**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5940**
**07.07.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 22 сентябрендәге 4954 номерлы карары (Башкарма комитетның 2023 елның 24 мартындагы 2087 номерлы карары редакциясендә) белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасының 8 бүлегенә, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | «Аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар белән адреслы профилактик чараларда катнашу өчен коммерцияле булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм җәмәгать активистларын стимуллаштыру чараларын тормышка ашыру | Коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча), Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге | 2023-2025 | Җәмәгать активистларын җәлеп итеп, профилактик эшкә җәлеп ителгән «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар өлеше, % | - | - | 20 | 30 | 20,0 | 20,0 | 20,0» |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов